ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ**

08. 11. 2018 г. Казань № 173-од

Фәнни-тикшеренү эшләре конкурсы турында

Архив документларына нигезләнгән гуманитар тикшеренүләр өлкәсендә фәнни-тикшеренү эшләрен гамәлгә ашыручы затларга ярдәм күрсәтү, шулай ук Татарстан Республикасы тарихын һәм документаль мирасын саклап калу, үстерү шартларын тудыру максатларында боерык бирәм:

1. Фәнни-тикшеренү эшләре конкурсын оештырырга һәм 2018 елның 3 декабреннән алып 2019 елның 1 сентябренә кадәр үткәрергә.
2. Кушымта итеп бирелгән Фәнни-тикшеренү эшләре конкурсы турында нигезләмәне расларга.
3. Архив документларын фәнни максатларда файдалану һәм халыкара элемтәләр бүлегенә конкурсның оештыру-методик ягын тәэмин итәргә.
4. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
5. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Рәис Г.З. Габдрахманова

Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитетының 2018 елның 8 ноябрендәге 173-од номерлы боерыгы белән
РАСЛАНДЫ

Фәнни-тикшеренү эшләре конкурсы турында
# НИГЕЗЛӘМӘ

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Фәнни-тикшеренү эшләре конкурсы турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә, конкурс) конкурсны оештыру һәм үткәрү тәртибен, конкурс эшләрен бәяләү критерийларын билгели.

1.2. Конкурсны оештыручы – Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты (алга таба – ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты).

1.2. Конкурс гавами була һәм хәзерге чор тарихи өйрәнүләрен исәпкә алган ачыклык һәм коллегиальлек принципларына нигезләнеп үткәрелә.

1.4. Конкурста фәнни-тикшеренү эшен башкаручы 18 яшьтән өлкәнрәк физик затлар катнашырга хокуклы.

1.5. Конкурс 2018 елның 3 декабреннән алып 2019 елның 1 сентябренә кадәр үткәрелә.

1.6. Үткәрү тәртибе, сроклары, шартлары һәм конкурста катнашу өчен сайлап алу критерийлары турында мәгълүмат ТР Архив эше буенча дәүләт комитетының “Фәнни-тикшеренү эшләре конкурсы турында” боерыгы үз көченә кергән көннән алып 3 эш көне эчендә ТР Архив эше буенча дәүләт комитетының рәсми сайтына (www.http://arhiv.tatarstan.ru/) урнаштырыла.

## II. Конкурсның максаты һәм бурычы

2.1. Конкурсның максаты фәнни-тикшеренү эшләрен гамәлгә ашыручы затларга ярдәм күрсәтүдән, татар халкы тарихын һәм документаль мирасын саклап калу, үстерү шартларын тудырудан гыйбарәт.

2.2. Конкурсның бурычы Татарстан Республикасы Архив фонды документларын фәнни һәм иҗтимагый әйләнешкә даими, максатчан кертүне тәэмин итә торган иң яхшы фәнни-тикшеренү эшләрен ачыклаудан гыйбарәт.

## III. Конкурсны үткәрү шартлары һәм тәртибе

3.1. Конкурс 2018 елның 3 декабреннән алып 2019 елның 1 сентябренә кадәр ике этапта үткәрелә:

беренче этап:

гаризалар бирү һәм табылган документлар исемлекләрен конкурска тапшыру (2018 елның 3 декабреннән алып 10 декабренә кадәр);

тапшырылган документациягә нигезләнеп, гаризалар рейтингын төзү һәм табылган документларның исемлекләрен фәнни-тикшеренү эшенең темасы буенча карау (2018 елның 11 декабреннән алып 17 декабренә кадәр);

икенче этап:

фәнни-тикшеренү эшен әзерләү һәм тапшыру (2018 елның 21 декабреннән алып 2019 елның 1 сентябренә кадәр).

Конкурсны оештыручы конкурста катнашучылардан тапшырылган материаллар буенча тиешле документация белән бергә аңлатмалар соратып алырга хокуклы.

3.2. Конкурс түбәндәге юнәлешләр буенча үткәрелә:

Идел буенда ислам: тарих, социология һәм чыганакларны өйрәнү;

Идел буеның һәм Урал буеның социаль тарихы;

татар халкының тарихи һәм мәдәни мирасын популярлаштыру;

шәһәр тикшеренүләре (урбанистика, колонизация, дин һ.б.ш.);

татар халкының традицион мәдәнияте (этнографиясе);

Татарстан АССРдан чакырылучылар буенча исәпкә алу документларын барлау (1941-1945 еллар);

Георгий кавалерлары – Беренче Бөтендөнья сугышы елларында мөселманнар (1914-1918 еллар).

3.3. Конкурста катнашучылар әлеге Нигезләмәдә каралган сайлап алынган юнәлешләрнең берсе буенча табылган документлар исемлекләрен тапшыра.

3.4. Катнашучылар конкурсның беренче этабында катнашу өчен түбәндәге документлар тапшыра:

күрсәтелгән форма буенча тутырылган катнашучы гаризасы (1 нче кушымта) һәм күз алдында тотылган фәнни-тикшеренү эше темасы буенча табылган документларның исемлеге;

персональ белешмәләрне эшкәртүгә рөхсәт (2 нче кушымта).

Конкурсның беренче этабына документлар ТР Архив эше буенча дәүләт комитетына әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы өченче абзацында күрсәтелгән срокларда юллана.

3.5. Конкурсның беренче этабы нәтиҗәсе фәнни-тикшеренү эше темасы буенча табылган документларның исемлеге, икенче этапныкы – фәнни-тикшеренү эше була.

Конкурсның беренче этабында тапшырылган документларга нигезләнеп һәм әлеге Нигезләмәнең 4.1 пунктына ярашлы рәвештә жюри конкурсның икенче этабында катнашуны дәвам иттерү турында карар кабул итә.

3.6. Конкурста катнашырга рөхсәт бирүдән баш тарту өчен гаризаның әлеге Нигезләмәнең 3.3 пунктында һәм 1 нче кушымтада күрсәтелгән таләпләргә туры килмәве, документларның тулы күләмдә тапшырылмавы һәм аларны тапшыруның әлеге Нигезләмәнең 3.8 пунктында билгеләнгән срок бозылып тапшырылуы нигез була.

3.7. Конкурста катнаштырудан баш тартылган затларның һәм конкурсның икенче этабына үткәрелгән затларның исемлекләре жюри утырышы үткәрелгән көннән алып 5 эш көне эчендә жюри утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә һәм ТР Архив эше буенча дәүләт комитетының рәсми сайтына урнаштырыла.

3.8. Конкурсның беренче этабына документлар пакеты 2018 елның 3 декабреннән алып 10 декабрена кадәр электрон рәвештә konkurs.nir@mail.ru электрон почта адресына җибәрелә һәм/яки кулдан тапшырыла, почта аша ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты адресына юллана: 420107, Казан ш., Ново-Песочная ур., 44, “Фәнни-тикшеренү эшләре конкурсы” тамгасы белән.

## IV. Конкурс эшләрен бәяләү критерийлары

4.1. Эшләрне конкурсның беренче этабында бәяләү критерийлары:

конкурсның максатларына һәм бурычларына туры килү;

файдаланган материалның тулылыгы (1 нче кушымтага ярашлы рәвештә);

кимендә ике телдәге (рус, татар, инглиз, иске татар, төрек, гарәп, фарсы) чыганаклардан файдалану;

архив документларын файдалану.

4.2. Эшләрне конкурсның икенче этабында бәяләү критерийлары:

конкурсның максатларына һәм бурычларына туры килү;

кимендә ике телдәге (рус, татар, инглиз, иске татар, төрек, гарәп, фарсы) чыганаклардан файдалану;

архив документларын файдалану;

тәкъдим ителгән фәнни-тикшеренү эшенә кимендә ике рецензия булу;

фәнни-тикшеренү эше төзелешенең СССРда тарихи документларны бастыру кагыйдәләренә (М., 1990) туры килүе.

## V. Конкурстагы жюри

5.1. Фәнни-тикшеренү эше темасы буенча табылган документларның исемлекләрен бәяләүне һәм фәнни-тикшеренү эшен бәяләүне башкару максатларында жюри төзелә.

5.2. Жюри ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты, “Татарстан Республикасы Дәүләт архивы” Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе вәкилләреннән, фәнни бергәлек вәкилләреннән, ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты каршындагы Иҗтимагый совет әгъзаларыннан жюри рәисе һәм әгъзалары

составында кимендә 9 кешедән төзелә. Жюри составы ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты боерыгы белән раслана.

5.3. Фәнни-тикшеренү эше темасы буенча табылган документларның исемлекләрен бәяләгәндә һәм фәнни-тикшеренү эшен бәяләгәндә түбәндәгеләр тәэмин ителә:

гаризаны һәм фәнни-тикшеренү эше темасы буенча табылган документларның исемлекләрен бәяләүнең бәяләү критерийлары нигезендә объективлылыгы;

конфиденциальлек.

5.4. Гаризаны һәм фәнни-тикшеренү эше темасы буенча табылган документларның исемлекләрен һәм фәнни-тикшеренү эшләрен бәяләү жюри әгъзалары тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 4.1, 4.2 пунктларында каралган бәяләү критерийларына нигезләнеп башкарыла.

5.5. Жюри әгъзалары һәр критерий буенча балл куя, һәм алар кушыла. Һәр критерий буенча балл саны 10-баллы шкала буенча (0 алып 10 кадәр) билгеләнә.

Баллар “Жюри бәяләмәсенә” язып куела, жюри әгъзасы имзасы белән таныклана һәм жюри рәисенә тапшырыла (3 нче, 4 нче кушымталар).

5.6. Конкурс эшләрен бәяләүнең әлеге Нигезләмәдәге критерийлары буенча жюри әгъзалары тарафыннан куелган балларны кушканнан соң чыккан нәтиҗәләр буенча катнашучыларның йомгак рейтингы төзелә, ул жюри рәисе һәм әгъзалары тарафыннан имзалана.

5.7. Жюри утырышы, жюри әгъзаларының гомуми саныннан 2/3 өлеше катнашкан очракта, хокукка ия дип санала.

5.8. Жюри карарлары утырышта булган әгъзалары саныннан тавышларның гади күпчелеге белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта жюри рәисе тавышы хәлиткеч була.

5.9. Жюри карарлары беркетмәләр белән рәсмиләштерелә.

## IV. Конкурс этапларының җиңүчеләрен билгеләү тәртибе

6.1. Документлар пакетын тапшыру төгәлләнгәннән соң 3 эш көненнән дә соңга калмыйча жюри утырышы үткәрелә.

6.2. Конкурсның беренче этабы җиңүчеләре исемлеге, катнашучыларның йомгак рейтингына нигезләнеп, жюри бәяләүләренә ярашлы рәвештә төзелә һәм, жюри утырышы беркетмәсенә нигезләнеп, беркетмә имзаланган көннән алып 3 эш көненнән дә соңга калмыйча ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты рәисе боерыгы белән раслана һәм ТР Архив эше буенча дәүләт комитетының рәсми сайтына урнаштырыла.

6.3. Жюри бәяләве нәтиҗәләренең кушма күрсәткече буенча рейтингта беренче алты урынны алган катнашучылар конкурсның беренче этабы җиңүчеләре дип таныла.

6.4. Конкурсны финанслау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 27 сентябрендәге 2559-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә гамәлгә ашырыла.

6.5. Конкурсның беренче этабы җиңүчеләренә фәнни-тикшеренү эшен табылган документларны исәпкә алып алга таба башкару өчен акчалата түләү бирелә (Федераль архив агентлыгы буйсынуындагы федераль казна учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтү буенча рекомендацияләр нигезендә).

6.6. Конкурсның беренче этабы җиңүчеләре, 2019 елның 1 сентябреннән дә соңга калмыйча, ТР Архив эше буенча дәүләт комитетына акчалата түләүне куллану турында хисап тапшыралар.

6.7. Фәнни-тикшеренү эшләрен тапшыру төгәлләнгәннән соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, жюри утырышы үткәрелә.

6.8. Жюри бәяләве нәтиҗәләренең кушма күрсәткече буенча рейтингта беренче өч урынны алган катнашучылар конкурсның икенче этабы җиңүчеләре дип таныла.

6.9. Конкурсның икенче этабы җиңүчеләре исемлеге жюри бәяләвенә нигезләнеп төзелә, жюри утырышы беркетмәсенә нигезләнеп, беркетмә имзаланган көннән алып 3 эш көненнән дә соңга калмыйча, ТР Архив эше буенча дәүләт комитеты рәисе боерыгы белән раслана һәм ТР Архив эше буенча дәүләт комитетының рәсми сайтына урнаштырыла.

6.10. Конкурсның икенче этабы җиңүчеләренә фәнни-тикшеренү эшен җыентык рәвешендә бастырып чыгару өчен акчалата түләү башкарыла, ул күрсәтелгән эшнең күләменнән һәм аны чыгару (кимендә 3) эшләрен үтәүгә каралган коммерция тәкъдимнәреннән чыгып билгеләнә.

6.11. Конкурсның икенче этабы җиңүчеләре 2019 елның 31 декабренә кадәр ТР Архив эше буенча дәүләт комитетына нәшер ителгән җыентыкның 1 нөсхәсен тапшыра.

6.12. Конкурсның катнашучылары ТР Архив эше буенча дәүләт комитетына тапшырыла торган материалларның дөреслеген, шулай ук ТР Архив эше буенча дәүләт комитетына тапшырыла торган материалларны эшләгәндә өченче затларның авторлык һәм башка хокуклары бозылмауны гарантиялиләр.

Әлеге шарт бозылган, шулай ук акчалата түләүләр максатчан кулланылмаган очракта, конкурсның җиңүчеләренә бүлеп бирелгән акчалар законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

6.13. Фәнни-тикшеренү эшенә бердәнбер хокук ТР Архив эше буенча дәүләт комитетында кала.

Фәнни-тикшеренү эшләре
конкурсы турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

Фәнни-тикшеренү эшләре конкурсында катнашуга гариза

1. Гариза бирүче:
Ф.И.А.и.:

____________________________________________

____________________________________________

________________________________

Туу датасы:

____________________________________________

Эш урыны, биләгән вазыйфа:

____________________________________________

Гыйльми дәрәҗә:

____________________________________________

Яшәү урынының тулы адресы:

____________________________________________

Паспорт белешмәләре (кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән):

____________________________________________

Тел.: ____________________________________________

e-mail:

____________________________________________

2. Күз алдында тотылган фәнни-тикшеренү эше темасы:

____________________________________________

____________________________________________

________________________________

3. Табылган документлар исемлеге:

____________________________________________

____________________________________________

4. Фәнни-тикшеренү эшенең кыскача эчтәлеге (эшнең максатлары һәм бурычлары, төп бүлекләренең кыскача эчтәлеге):

____________________________________________

____________________________________________

____________________________________________

______________________________________________________________________________

________________________________________________

5. Чаралар планы (төп чараларның тасвирламасы, проектны гамәлгә ашыру этаплары һәм сроклары):

| т/б № | Гамәлгә ашыру этабы | Чараның исеме | Гамәлгә ашыру сроклары |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| | | | |

Гаризада күрсәтелгән барлык мәгълүматның, шулай ук өстәмә материалларның дөрес һәм хак булуын, өченче затлар хокукларының бозылмавын белдерәм һәм минем тарафтан бирелгән белешмәләргә өстәмә аңлатма бирә торган мәгълүматны эш урыны буенча һәм дәүләт һәм муниципаль хакимият органнарыннан соратып алу гамәлен башкару өчен моңа вәкаләтле координаторга рөхсәт бирәм.

Гариза бирүченең Ф.И.А.и. ___________________________________/_______________/

(имза)

Фәнни-тикшеренү эшләре конкурсы
турында нигезләмәгә
2 нче кушымта

Персональ мәгълүматларны эшкәртүгә, тапшыруга һәм таратуга
рөхсәт

Фәнни-тикшеренү эшләре конкурсындагы түбәндәге күләмдә персональ мәгълүматларымны “Персональ мәгълүматлар турында” 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен исәпкә алып эшкәртүгә, тапшыруга һәм таратуга (аларны миннән һәм/яки теләсә кайсы өченче заттан алуны да кертеп) рөхсәт бирәм:

Эшкәртелә торган персональ мәгълүматлар исемлеге (Ф.И. А.и. (соңгысы – булган очракта), җенес, туу датасы һәм урыны, гражданлык, шәхесне таныклый торган документның реквизитлары (документның төре, сериясе һәм номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән), яшәү урыны, теркәлү урыны, телефон номеры (шул исәптән кәрәзле телефон номеры), электрон почта адресы)

____________________________________________________________

(Ф.И.А.и. (соңгысы – булган очракта), имза)

________________________

(дата)

Фәнни-тикшеренү эшләре
конкурсы турында нигезлә
3 нче кушымта

ЖЮРИ БӘЯЛӘМӘСЕ

Гариза №________ ,«__»_____________,_______ ел

| | |
|---|---|
| Жюри вәкиленең Ф.И.А.и. | |
| Гариза бирүченең Ф.И.А.и. | |

Эшләрне конкурсның беренче этабында бәяләү критерийлары

| Бәяләү критерийлары | 0 баллдан алып 10 баллга кадәр |
|---|---|
| 1. Конкурсның максатларына һәм бурычларына туры килү | |
| 2. Файдаланган материалның тулылыгы (1 нче кушымтага ярашлы рәвештә) | |
| 3. Кимендә ике телдәге (рус, татар, инглиз, иске татар, төрек, гарәп, фарсы) чыганаклардан файдалану | |
| 4. Архив документларын файдалану | |
| БАРЛЫГЫ, балл | |

«___»____________, 2018 ел
Жюри әгъзасы имзасы ________________
Имзаны ачып күрсәтү ______________________

Фәнни-тикшеренү эшләре конкурсы
турында нигезләмәгә
4 нче кушымта

## ЖЮРИ БӘЯЛӘМӘСЕ

Гариза №_______ ,«__»____________,______ ел

| | |
|---|---|
| Жюри вәкиленең Ф.И.А.и. | |
| Гариза бирүченең Ф.И.А.и. | |

Эшләрне конкурсның икенче этабында бәяләү критерийлары

| Бәяләү критерийлары | 0 баллдан алып 10 баллга кадәр |
|---|---|
| 1. Конкурсның максатларына һәм бурычларына туры килү | |
| 2. Кимендә ике телдәге (рус, татар, инглиз, иске татар, төрек, гарәп, фарсы) чыганаклардан файдалану | |
| 3. Архив документларын файдалану | |
| 4. Тәкъдим ителгән фәнни-тикшеренү эшенә кимендә ике рецензия булу | |
| 5. Фәнни-тикшеренү эше төзелешенең СССРда тарихи документларны бастыру кагыйдәләренә (М., 1990) туры килүе | |
| БАРЛЫГЫ, балл | |

«___»___________, 2018 ел
Жюри әгъзасы имзасы _______________
Имзаны ачып күрсәтү _____________________